| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 07.03.2020 | | № 119 |

**2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасы»на) үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2019 елның 31 августындагы 306 номерлы боерыгы белән расланган 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасына») кушымта нигезендә үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «07» мартындагы
119 номерлы боерыгына
кушымта

**2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасы»на) кертелә торган үзгәрешләр**

1. I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.4 пунктын өстәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы стратегик һәм программа документларының Татарстан Республикасында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү базарларында аларны гамәлгә ашыру конкурентлыкның торышына йогынты ясый торган чаралар кертелгән исемлеге кушымтада бирелә.».

2. II бүлекнең таблицасында:

а) 1 пунктның 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « | 1.1 | Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программаларын тормышка ашыручы хосусый мәгариф оешмаларының, хосусый эшкуарларның белем бирү | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында белем алучы балаларның гомуми исәбендә хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның | про-цент | 1,27 | 1,57 | 1,58 | 1,59 | 1,6 | V = A / B x 100%, биредә: A – хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балалар саны, кеше; B – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы балаларның гомуми саны, кеше | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлегенә чыгымнарны субсидияләү | чагыштырма өлеше | | | | | | | | |

»;

б) 6 пунктта:

«Максат (төп күрсәткеч): Татарстан Республикасы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан сатып җибәрелгән җылылык энергиясенең гомуми күләмендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар тарафыннан сатып җибәрелгән җылылык энергиясенең файдалы куллану өлешен саклап калу, процент» сүзләрен «Максат (төп күрсәткеч): җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясен җитештерү) өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен саклап калу, процент» сүзләренә алмаштырырга;

«Фаразлана торган күрсәткечләр:
01.01.2020 – 67 %
01.01.2021 – 67 %
01.01.2022 – 67 %»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«Фаразлана торган күрсәткечләр:
01.01.2020 – 68 %
01.01.2021 – 68,1 %
01.01.2022 – 68,2 %»;

в) 8 пунктта:

«Төп күрсәткечләр:
01.01.2018 – 98,1 %
01.01.2019 – 98,2 %
Фаразлана торган күрсәткечләр:
01.01.2020 – 80 % *
01.01.2021 – 86,1 %
01.01.2022 – 86,3 %

* 2020 елда күрсәткечләрнең кимүе лицензия алырга кирәклек белән аңлатыла (һәр 5 ел саен), нәтиҗәдә, ИКнең бер өлеше гамәлдәге законнар кысаларында лицензия алмыйча базардан китәчәк.»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«Төп күрсәткечләр:
01.01.2018 – 85,8 %
01.01.2019 – 86 %
Фаразлана торган күрсәткечләр:
01.01.2020 – 86,1 %
01.01.2021 – 86,2 %
01.01.2022 – 86,3 %»;

8.1 һәм 8.2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8.1 | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын арттыру хисабына торак-коммуналь комплексы оешмаларының конкурентлылык сәләтен арттыру | Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә әзерлек, яңадан һөнәри әзерлек һәм квалификациясен күтәрү узган хезмәткәрләр саны | кеше | 2102 | 3026 | 3028 | 3030 | 3032 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 8.2 | Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык турында законнарны үтәүне контрольдә тотуның нәтиҗәлелеген арттыру | Мөрәҗәгать итүчеләрнең күзәтчелек органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итү, гаризаларның керүен онлайн режимда контрольдә тоту өчен кире элемтә каналларының яңа рәвешләрен кулланышка кертү | берәмлек | 3 | 7 | 8 | 9 | 10 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе |

»;

г) 10 пунктта:

«Татарстан Республикасы-Энерготрейдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм башкалар) гамәлгә ашыра» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гарантияле тәэмин итүче – «Татэнергосбыт» АҖ тарафыннан кулланучыларга 17,9 млрд.кВт/сәгать диярлек электр энергиясе тапшырыла»;

«Максат (төп күрсәткеч): Татарстан Республикасында сатылган электр энергиясенең гомуми күләмендә электр энергиясен (егәрлек) ваклап сату базарында электр энергиясен (егәрлек) сату-алу өлкәсендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар тарафыннан сатылган электр энергиясе (егәрлек) өлешен арттыру, процент» сүзләрен «Максат (төп күрсәткеч): электр энергиясен (егәрлек) ваклап сату базарында электр энергиясен (егәрлек) сату-алу өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру, процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 12 пунктта:

«Максат (төп күрсәткеч): мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы хосусый милек рәвешендәге медицина оешмалары өлешен арттыру, процент» сүзләрен «Максат (төп күрсәткеч): мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын гамәлгә ашыруда катнаша торган хосусый сәламәтлек саклау системасы медицина оешмалары өлешен арттыру, процент» сүзләренә алмаштырырга;

12.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « 12.2 | Сәламәтлек саклау оешмаларына сыйфат менеджменты системаларын гамәлгә кертүдә ярдәм итү | Сыйфат менеджменты системасы кулланыла торган сәламәтлек саклау оешмалары өлеше (V) | про-цент | 38,5 | 40,5 | 41 | 41,5 | 42 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – сыйфат менеджменты системасы кулланыла торган керткән сәламәтлек саклау оешмалары саны, берәмлек;<br>B – сәламәтлек саклау оешмаларының гомуми саны, берәмлек | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы »; |

е) 14 пунктның 14.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « 14.1 | Физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны иртә | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән | про-цент | 1,5 | 1,5 | 2,5 | 2,7 | 3 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | диагностикалау, социализацияләү һәм реабилитацияләү хезмәтләре күрсәтүче хосусый милек рәвешендәге оешмалар санын арттыру | балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү өлкәсендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлеше (V) | | | | | | | психологик-педагогик ярдәм күрсәтү өлкәсендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлеше, берәмлек;<br>B – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү базарында эшләүче барлык оешмалар (милекнең барлык рәвешендәге) Россия Федерациясе хуҗалык итүче субъектларыннан тыш: 50% тан артык, федераль дәүләт унитар предприятиеләрдән, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләреннән, федераль автоном учреждениеләреннән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) саны, берәмлек | |

»;

ж) 16 пунктның 16.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « 16.1 | Дәүләт-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, муниципальара маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртүнең хосусый милек рәвешендәге пассажирлар йөртү секторын үстерү | Татарстан Республикасында регуляр муниципальара маршрутларда автомобиль транспортында пассажир йөртүчеләрнең гомуми санында регуляр муниципальара маршрутларда милекнең хосусый рәвешендәге пассажирлар йөртүчеләр өлеше (V) | про-цент | 86 | 91 | 92 | 93 | 94 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – регуляр муниципальара маршрутларда автомобиль транспортында дәүләтнеке булмаган (муниципаль булмаган) пассажир йөртүчеләр саны, берәмлекләрдә;<br>B – регуляр муниципальара маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртү маршрутларында муниципалитетлар арасында пассажир йөртүчеләрнең гомуми саны, берәмлекләрдә | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы »; |

з) 18 пунктның 18.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « 18.1 | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә конкурентлыкны үстерү | Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының | про-цент | 9,7 | 9,7 | 13,2 | 13,4 | 13,6 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (милекнең барлык рәвешләрендәге) гомуми санында Татарстан Республикасында фактта социаль хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының чагыштырмача өлеше (V) | | | | | | | оешмалары саны, берәмлекләрдә;<br>В – Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүче барлык социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (аларда Россия Федерациясе катнашу өлеше 50% тан артык булган хуҗалык субъектларыннан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрдән, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләреннән, федераль автоном учреждениеләреннән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) гомуми саны, берәмлекләрдә | |

»;

и) 19 пунктның 19.1 һәм 19.2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « | 19.1 | Мәдәният өлкәсендә дәүләтнеке булмаган (муниципаль булмаган) оешмалар секторын, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык һәм муниципаль хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, үстерү | Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә һәм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның гомуми күләмендә хосусый милек рәвешендәге оешмаларга бүлеп бирелгән бюджет акчаларының өлеше (V) | про-цент | 1,9 | 1,8 | 4,2 | 4,3 | 4,4 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – хосусый милек рәвешендәге оешмаларга мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә һәм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән бюджет акчалары күләме, млн. сумнарда;<br>B – мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә һәм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчаларның гомуми күләме, млн сумнарда | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| | 19.2 | Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын арттыру | Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфаты дәрәҗәсе | про-цент | 88 | 96 | 97 | 98 | 99 | Абсолют күрсәткеч. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан үткәрелә торган еллык социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча билгеләнә | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе »; |

к) 20 пунктта:

20.1 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

20.2 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

л) 21 пунктта:

21.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « 21.2 | Республика товар җитештерүчеләренең «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» конкурсында катнашуы | «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» конкурсында катнашучы оешмаларның гомуми санында «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсының федераль этабына узган | процент | 62 | 57 | 58 | 59 | 61 | V = A / B x 100%, монда:<br>A – кулланучылар товарлары төркеме буенча «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсының федераль этабына узган оешмалар саны, берәмлекләрдә;<br>B – кулланучылар товарлары төркеме буенча «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» еллык конкурсында катнашкан оешмалар, шул исәптән | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге (килешү буенча) |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | оешмалар өлеше (V) | | | | | | | Татарстан Республикасы җитештерүчеләренең гомуми саны, берәмлекләрдә | |

»;

21.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21.4 | Халык өчен торак йортларга якын урнашкан кибетләрдән (өй янындагы кибетләр) продукция сатып алу мөмкинлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2016 елның 7 октябрендәге 259-од номерлы боерыгы нигезендә расланган торак объектларның урнашу нормати-вының үтәлмәве (V) | про-цент | 128 | 128 | 129 | 130 | 131 | V = A / B x 100%, биредә:<br>A – сәүдә объектлары белән тәэминителү, кв. метр;<br>B – сәүдә объектлары белән тәэмин ителү нормативы, кв. метр | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |

»;

м) 23 пунктта:

пунктның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Торак төзелеше базары (Мәскәүнең торак төзелеше һәм индивидуаль торак төзелеше реновация фондыннан тыш)»;

«Максат (төп күрсәткеч): нәселле терлек үрчетү базарында хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлешен арттыру, процентларда» сүзләрен «Максат (төп күрсәткеч): нәселле терлек үрчетү базарында хосусый милек рәвешендәге оешмалар өлешен арттыру (Мәскәүнең торак төзелеше һәм индивидуаль торак төзелеше реновация фондыннан тыш), процентларда» сүзләренә алмаштырырга;

н) 40 пунктта «1500 кадастр инженеры» сүзләрен «1700 кадастр инженеры» сүзләренә алмаштырырга;

3. III бүлекнең таблицасында:

а) 4 пунктның 4.1 пунктчасында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктның 6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « | 6.1 | Татарстан Республикасының конкурентлы базарларында муниципаль предприятиеләр санын киметү | Юкка чыгарылган/ үзгәртеп корылган муниципаль унитар предприятиеләр саны | берәмлек | 1 | 1 | 2 | 3 | 4 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |

»;

в) 15 пунктның 15.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « | 15.1 | Эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүдә ярдәм итүне оештыру | Эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүчеләр санында хисап | процент | 0,3 | 0,3 | 0,33 | 0,36 | 0,4 | V = A / B x 100%, биредә:<br>А – эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүдә ярдәм ителгән гражданнар саны, кеше.<br>В – хисап чорында теркәлгән эшсезләр саны, кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чорында теркәлгән эшчесезләр санына карата өлеше (V) | | | | | | | | »; |

г) 25 пунктның 25.1 пунктчасында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

д) 26 пунктта:

26.1 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

26.2 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

е) 28 пунктта:

пунктның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| « | 28 | Конкурентлы мохитне үстерүгә юнәлдерелгән, билгеләнгән нәтиҗәләргә (максатларга) ирешүне тәэмин итә торган системалы өстәмә чаралар | »; |

28.1.1 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

28.3.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| « | 28.3.1 | Фәнни-техник өлкәдә, шул исәптән дисциплинарара өлкәдә тикшеренүләрне | «Умник», «Умник на старт», «Старт», «Развитие», «Коммерциализация» һәм «Кооперация» | берәмлек | 64 | 104 | 105 | 106 | 107 | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үстерүгә ярдәм итү | федераль программа-ларында катнашкан предприятиеләр саны | | | | | | | | |

»;

түбәндәге эчтәлекле 28.4–28.8 пунктчалар өстәргә:

«

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28.4 | Кирәгеннән артык дәүләт һәм муниципаль җайга салуны бетерү өчен шартлар тудыру. Административ киртәләрне киметү | | | | | | | | | |
| 28.4.1 | «Сыналган бизнес» интернет-порталын үстерү | Эшкуарларның «Сыналган бизнес» интернет-порталында бастырылган Татарстан Республикасында күзәтчелек органнары тарафыннан ачыклана торган типик хокук бозулары турында белешмәлекләр саны | берәм-лек | 375 | 380 | 400 | 430 | 450 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 28.5 | Экспорт эшчәнлеге өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүгә булышлык күрсәтү | | | | | | | | | |
| 28.5.1 | Экспорт эшчәнлеге өлкәсендә кече һәм урта эшкуарларга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү | Экспорт контрактлары төзегән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны | берәм-лек | 23 | 26 | 27 | 28 | 29 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28.5.2 | Кече һәм урта компанияләрнең инновацияле продукциясен тышкы базарларга чыгару | «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең Татарстан Республикасы Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан төбәкара һәм халыкара дәрәҗәләрдә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының инновацияле продукциясен таныту буенча үткәрелгән чаралар саны, шул исәптән бизнес-миссияләр оештыру, күргәзмә эшчәнлегенә ярдәм итү һ.б. | берәм-лек | 22 | 29 | 30 | 31 | 32 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 28.6 | Россия Федерациясе субъектларында Конкурентлыкны үстерү стандарты нигезендә Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерү механизмын (алгоритмын) тарату (тиражлау) | | | | | | | | | |
| 28.6.1 | Экспорт эшчәнлеге өлкәсендә кече һәм урта | Монополиягә каршы федераль хезмәтнең | Үткә-релгән зона | 41 | 42 | 43 | 44 | 45 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшкуарларга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары белән зональ киңәшмәләр уздыру | киңәш-мәләре саны | | | | | | | министрлыгы |
| 28.6.2 | Конкурентлыкның торышы һәм Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә булышлык итү эшчәнлеге турында эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының һәм товарлардан, эшләрдән, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы-ларның мәгълүматлы булу дәрәҗәсен арттыру | Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү эшчәнлеге турында мәгълүматны Татарстан Республикасының инвестиция порталында, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары рәсми сайтларында һәм конкурентлыкны үстерү буенча | Квар-талга бер тапкыр | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуни-кация челтәрендәге сайтында урнаштыру | | | | | | | | |
| 28.7 | Эшкуарлык мохите өчен инфраструктура булдыру һәм үстерү | | | | | | | | | |
| 28.6.1 | Индустриаль парклар булдыру һәм үстерү, инновацияләр кертүгә һәм яңа технологик чишелешләрне кертү буенча хуҗалык итүче субъектларның мөмкинлекләрен арттыруга ярдәм итә торган институцион мохит булдыру юлы белән индустриаль паркларның идарә компанияләренә һәм резидентларына ярдәм итү | Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары белән зональ киңәшмәләр уздыру | Берәм-лек | 89 | 90 | 100 | 101 | 102 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28.8 | Товар һәм хезмәт күрсәтү базарында намуслы конкурентлыкны үстерүне тәэмин итү | | | | | | | | | |
| 28.8.1 | Эшкуарлар өчен укулар уздыру | Эшкуарларның белемен күтәрү | Кеше | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

»;

4. 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасы»на) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасына») кушымта

**Татарстан Республикасы стратегик һәм программа документларының Татарстан Республикасында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү базарларында аларны гамәлгә ашыру конкурентлыкның торышына йогынты ясый торган чаралар кертелгән исемлеге**

| **Чара** | **Стратегик/программа документы*** | **Җаваплы башкаручы** |
|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары | | |
| Мәктәпкәчә белем бирү хосусый оешмалары секторын җәелдерү | «2020 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем ала алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алу хокукын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары | |
| Балаларга өстәмә белем бирүдә хезмәт күрсәтү базары | | |
| Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый оешмаларны үстерү | «2020 елга Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ала алырлык һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары | |
| Күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм аларның агымдагы ремонты буенча эшләр башкару базары | | |
| Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кадрлар әзерләүне, һөнәри яктан яңадан укытуны һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыру | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 14 декабрендәге 2941-р номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәтләр күрсәтү базары | | |
| «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану буенча хезмәт күрсәтү базарында конкурентлыкны үстерү өчен шартлар тудыру | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга кластерлар нигезендә Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 елның 22 октябрендәге 763 номерлы карары | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| Балалар ялы һәм савыктыру буенча хезмәтләр күрсәтү базары | | |
| Санатория-курорт оешмаларына юлламалар бәясен тулысынча яки өлешчә компенсацияләү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| Ваклап сату базары | | |
| Ит һәм ит продуктлары җитештерүне оештыру өлкәләрендә эшкуарлыкның кече рәвешләрен үстерү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013–2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Авыл хуҗалыгына кош үрчетүне оештыру өлкәсендә эшкуарлыкның кече рәвешләрен, шулай ук авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын үстерү | | |
| Кош үрчетү, ит һәм ит продуктлары җитештерү буенча яңа комплекслар төзү һәм республикада булганнарын модернизацияләү | | |
| Нәселле терлекчелек базары | | |
| Нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә субсидияләр бирү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013–2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Орлыкчылык базары | | |
| Элиталы орлыклар сатып алуга чыгымнар өлешен кайтаруга субсидияләр бирү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013–2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | раслау турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары | |
| Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте объектлары белән идарә итү процессларын камилләштерү | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларына идарә процессларын оптимизацияләү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2022 елларга Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 декабрендәге 1140 номерлы карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| Яңа эшкуарлык инициативаларын стимуллаштыру | | |
| Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт финанс ярдәме күрсәтү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисад» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында түләнә торган кредитлар буенча процентларны түләү белән бәйле чыгымнарга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 24 сентябрендәге 873 номерлы карары | |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2014 елның 9 июлендәге 474 номерлы карары | |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2011 елның 31 октябрендәге 896 номерлы карары | |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2004 елның 17 ноябрендәге 498 номерлы карары | |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары | |
| Гамәли юнәлешле (дуаль) белем бирү механизмнарын һәм сәнәгатьнең арадаш эшче һөнәрләре буенча югары технологияле тармакларын кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын үстерү | | |
| Һөнәри осталык конкурсларын оештыру һәм уздыру ярдәмендә бөтен дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләрне һәм һөнәр стандартларын гармонияләштерү юлы белән эшче һөнәрләрнең абруен арттыру һәм һөнәри белем бирүне үстерү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2015 елның 25 сентябрендәге 707 номерлы карары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары | |
| Балаларның һәм яшьләрнең техник һәм фәнни-техник иҗатына ярдәм итү механизмнарын үстерү, шулай ук үз-үзеңне үстерүнең потенциаль мөмкинлекләре турында аларның мәгълүматлылыгын арттыру, фәнни, иҗади һәм эшкуарлык активлыгына ярдәм күрсәтүне тәэмин итү | | |
| Балаларның һәм яшьләрнең техник һәм фәнни-техник иҗатын хуплау механизмнарын үстерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «2019 елда укучыларны – гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының республика олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрне, бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм анда җиңүчеләрне һәм республика олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрне әзерләгән педагогика хезмәткәрләрен акчалата бүләкләү турында» 2019 елның 5 июнендәге под-892/19 номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары | |
| Инновацияләр кертүгә һәм хуҗалык итүче субъектларның яңа технологик чишелешләр кертү буенча мөмкинлекләрен арттыруга булыша торган институцион тирәлек һәм инновацион эшчәнлектә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына булышлык күрсәтү институтларын булдыруга һәм үстерүгә ярдәм күрсәтү | | |
| Татарстан Республикасында инновацион инфраструктура оешмаларын, шул исәптән төбәк инжиниринг үзәкләрен, прототиплаштыру үзәкләрен һәм Татарстан Республикасының Кластерлы үсеше үзәген эшләтү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018-2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү буенча чаралар планын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 9 августындагы 649 номерлы карары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы |
| Дисциплинарара тикшеренүләрне, шулай ук әлеге тикшеренүләр йомгаклары буенча алынган нәтиҗәләрне коммерциячел нигезгә һәм сәнәгать җитештерүе дәрәҗәсенә күчерү өчен шартлар тудыруны да кертеп, үстерүгә һәм хуплауга ярдәм итү | | |
| Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләнмәләр җитештерүгә дәүләт ярдәме | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карары | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында конкурентлыкны үстерү стандартының 33 пункты.

____________».